Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

11 ноябрь, 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Уставының 21.1 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Күн авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Күн авылында. Халык җыенын дүрт этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яңа, Урман, Мәктәп урамнары, Кави Шакиров урамының 1-25 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 30 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Кави Шакиров урамының 26-52 йортлары, Совет урамының 1-64 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2019 елның 3 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамының 65-117 йортлары, М.Конов урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2019 елның 6 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Комсомол, Тукай, Пионер урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Күн авыл җирлеге Күн торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән

(үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Әлбәдән авылында. Гражданнар җыенын 2019 елның 24 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Күл буе урамы, 25а йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Кун авыл җирлеге Әлбәдән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Кызыл Яшьләр авылында. Гражданнар җыенын 2019 елның 27 ноябрендә 8 сәгать 00 минутта Колхоз урамы, 9 нчы йорт янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Кун авыл җирлеге Кызыл Яшьләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү челтәрләрен урнаштыруны дәвам итү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кун авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кун авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов